**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Шешминка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены карары**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге составына керүче Андреевка авылында**

08 ноябрь 2019 ел №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегендә гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш.
2. Алынган чараларны җибәрергә:

- Андреевка торак пунктында зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (коймалар урнаштыру, ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Шешминка крепосте торак пунктында сууткәргеч челтәрләренең проект һәм эзләнү эшләре (инженерлык эзләнүләре, проект эшләре,проект экспертизасы), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Шешминка крепосте, Андреевка, Павловка, Нагай торак пунктларында урам утларын ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланылган электр энергиясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Шешминка крепосте һәм Андреевка торак пунктларында юл челтәрен кышкы чорда карап тоту һәм җәйге чорда чабу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу.

Халык җыенында рәислек итүче,
Шешминка авыл җирлеге башлыгы: М.Д.Шәйхетдинов